ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.07.2021 Казан ш. № 109-7/кс-2021

«РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте өчен агынты суларны транспортлауга тариф билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасына ярашлы рәвештә ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте (алга таба – «РСК» ҖЧҖ) өчен агынты суларны транспортлауга тариф билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тариф карар үз көченә кергән көннән башлап 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Ташландык суларны агызуны гамәлгә ашыручы «РСК» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятенә Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартларына туры китереп, ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көненнән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
07.07.2021 № 109-7/кс-2021
карарына кушымта

Ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «РСК» ЖЧҖ өчен
агынты суларны транспортлауга тариф

| №<br>т/с | Муниципаль берәмлекнең, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) су агызуны гамәлгә ашыручы оешманың атамасы | Агынты суларны транспортлаган өчен тариф<br>(бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|
| | | карар үз көченә кергән көннән башлап<br>07.07.2021 № 109-7/кс-2021 31.12.2021 кадәр |
| | Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге | |
| 1 | «РСК» ЖЧҖ (тарифлар өстәмә хак салымыннан башка күрсәтелгән) | 1,46 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге